Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

17 декабрь 2014г №16

«Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең 2015 нче елга һәм 2016, 2017 нче еллар план чорына бюджеты турында"

Депутат Билалов Н.С. чыгышын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Советы «Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең 2015 нче елга һәм 2016, 2017 нче еллар план чорына бюджеты турында» карар проекты халыкка җиткерелде һәм җирлек халкы белән фикер алышуның барлык кирәкле процедуралары узды, дип билгеләп үтә. Проект авыл җирлеге Советы депутатлары, хокук чыгару инициативасының башка субъектлары тарафыннан кертелгән фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып эшләп бетерелде. Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шулай ук Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының "Югары Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 32 статьясы нигезендә җирлек Советы карар кылды:

1 Статья

1. 2015 елга Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге бюджетының фаразланыла торган керем күләме 2305,1 мең сум күләмендә фаразлана.;

2) Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2305,1 мең сум.;

3) Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге бюджетының 0,0 мең сум күләмендә дефициты.

2. 2016 елга һәм 2017 елга Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге бюджетының 2016 елга фаразланыла торган керем күләме 2423,1 мең сум һәм 2017 елга 2612,0 мең сум күләмендә фаразлана.;

2) 2016 елга Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2423,1 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 45,2 мең сум күләмендә һәм 2017 елга 2612,0 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 105,2 мең сум күләмендә.;

3) Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең 2016 һәм 2017 елларга бюджет дефициты 0,0 мең сум күләмендә.

3. Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең 2015 елга һәм 2016, 2017 елларның план чорына бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2 Статья

1. 2016 елның 1 гыйнварына Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының иң югары чиген 0,00 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча бурычның иң югары чиген 0,00 мең сум күләмендә расларга.

2. 2017 елның 1 гыйнварына Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының иң югары чиген 0,00 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча бурычның иң югары чиген 0,00 мең сум күләмендә расларга.

3. 2018 елның 1 гыйнварына Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының иң югары чиген 0,00 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча бурычның иң югары чиген 0,00 мең сум күләмендә расларга.

4. 2015 елда Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең муниципаль бурычының иң чик күләмен 0,00 мең сум күләмендә, 2016 елда-0,00 мең сум, 2017 елда 0,00 мең сум күләмендә билгеләргә.

3 Статья

Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге бюджетында 2015 елга һәм 2016, 2017 еллар план чорына фаразланган керем күләмен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 Статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 60.1 статьясындагы 2 пункты нигезендә Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең 2015 елга һәм 2016, 2017 елларның план чорына бюджет керемнәрен бүлү нормативларын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

5 Статья

1. Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

6 Статья

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә 2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары, төркемнәре буенча бүлүне расларга.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге бюджетының 2015 елга һәм 2016 һәм 2017 еллар план

чорына чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге бюджетының 2015 елга-0 мең сум, 2016 елга-0 мең сум, 2017 елга 0 мең сум күләмендә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен расларга.

7 Статья

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "төзелгән килешүләр нигезендә Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр өлешен гамәлгә ашыру өчен Югары Чыршылы авыл җирлеге бюджетыннан Сарман муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара трансфертлар күләмен раслау турында" 2007 ел, 30 нчы июль, 318 нче номерлы карары: - 2015 елга авыл халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру буенча-759,4 мең сум, 2016 елга-826,6 мең сум, 2017 елга-973,7 мең сум. - 2015 елга җирле үзидарә органнарына бухгалтерлык хезмәте күрсәтү буенча 89,0 мең сум, 2016 елга 89,0 мең сум, 2017 елга 89,0 мең сум күләмендә.

8 Статья

Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге бюджетында СМР бюджетыннан алына торган акчаны исәпкә алырга:

1)җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр:
2015 елга-1877,2 мең сум.;
2016 елга-1991,5 мең сум.;
2017 елга-2208,6 мең сум.

2) җирлекләр бюджетларына бюджетларның балanslылыгын тәэмин итү буенча чараларга ярдәм итү өчен дотацияләр:
2015 елга-36,5 мең сум.;
2016 елга-34,8 мең сум.;
2017 елга-4,4 мең сум.

3) 2015 елга гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирлек бюджетларына 3,6 мең сум, 2016 елга 3,4 мең сум, 2017 елга 3,8 мең сум күләмендә субвенцияләр.

4) 2015 елга хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирлекләр бюджетларына 77,8 мең сум күләмендә, 2016 елга 78,8 мең сум күләмендә, 2017 елга 75,2 мең сум күләмендә субвенция күләме.

9 Статья

Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары 2015 елда һәм 2016, 2017 еллар план чорында муниципаль хезмәткәрләр, бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм оешмалары хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

10 Статья

Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге башкарма комитеты 2015-2017 елларда әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 абзацында каралган максатларга чыгымнарны гамәлгә ашырганнан соң, законда билгеләнгән тәртиптә гидротехник корылмаларны тотуга 50,0 мең сум күләмендә өстәмә керемнәр җибәрергә хокуклы.

11 Статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Югары Чыршылы авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

12 Статья

Әлеге карарны ТР, Сарман районы, Югары Чыршылы авылы адресы буенча урнашкан махсус урнаштырылган стендларда халыкка игълан итәргә: Югары Чыршылы авылы, Ленин ур., 40а йорт, Усай авылы, Азина ур., 11а йорт, Түбән Чыршылы авылы, Горький ур., 10а.

Сарман муниципаль районының рәсми сайтында «Район турында» бүлегендә урнаштырырга.

13 Статья

Әлеге карар 2015 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

14 Статья

Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Камалетдиновка әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл жирлеге
Советы Рәисе И.Н.Камалетдинов